Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 11**

Балыклы-Чүкәй авылы 2024 елның 1 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 2023 ел 2 маендагы № 8 "Җирле салымнар суммасы өлешендә бурычлылыкны җиткерергә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Муниципаль хокукый актны кануннарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге Советының 2.05.2023 № 8 «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарына (24.06.2024 № 3 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: 2 пунктның 1 һәм 2 пунктчаларын төшереп калдырырга.
2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чүкәй авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балыклы-Чүкәй авылы, Үзәк урамы, 8 йорт; Иске Арыш авылы, Үзәк урамы, 23А, Керәшен Казысы,Титов урамы йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya- sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чүкәй авыл җирлеге башлыгы: И.С.Мазитов